# Мәктәп яңа битләрдә... (хәзерге чор укытучылары)



## Мөхәмәдиева Ләйсинә Расил кызы

**2004-2009 нчы елларда Балалар һәм яшүсмерләр өчен “Наз” социаль приюты директоры, 2009 нчы елдан Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының Рәхмәт хаты иясе.**

1986 нчы елда Казан дәүләт педагогия институтының математика факультитын тәмамлап, хезмәт юлын Метрәй урта мәктәбендә математика укытучысы булып башлый. Бер ел эшләгәннән соң, Күбәк урта мәктәбенә күчерелә. Класс белән үрнәк эш оештыруын күреп, 1987 нче елда вожатый вазифасын да йөклиләр. Ләйсинә Расиловна үз эшен иҗади якын килеп, бөтен көчен, сәләтен биреп, яратып эшли. Ул җитәкләгән дружина район күләмендә алдынгылыкны бирми. Мәктәптә комсомол яшьләр вожагы да була. 1989 нчы елда оештыру сәләтен, тырыш, тынгысыз, төгәл булуын исәпкә алып, Ләйсинә Расиловнаны Бөтенсоюз Ленинчыл Коммунистик Яшьләр Союзының район комитетына өченче секретарь итеп билгелиләр. Укучы яшьләр белән үткәргән чараларны хәзер дә сагынып иска ала. “Ул вакытта Пионерлар йорты җитәкчесе Наилә Салиховна Сөләйманова белән берлектә мәктәп пионервожатыйлары, укытучы һәм укучы комсомол комитеты җитәкчеләренең “Урман иле” пионерлагерында оештырган уку-сменалары бик якты хатирә булып күңелдә калган”, - ди Ләйсинә Расиловна.

1991нче елда пионер, комсомол оешмалары таркала. Ләйсинә Расиловна Октябрь урта мәктәбендә математика укытучысы һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшли башлый.

1995 нче елда яңадан Күбәк урта мәктәбенә укытырга кайта. Аның кешеләргә карата игътибарлы, үтемле сүзле, киң эрудицияле белгеч булуын исәпкә алып, 2004 елда Дәүләт бюджет учреждениесе «Татарсан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәкмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мөслим муниципаль районындагы балалар һәм яшүсмерләр өчен “Наз” социаль приюты” директоры

итеп билгеләнелә. Якын-тирә районнарда бердәнбер оешма буларак, аннан бу вазифаны башкару зур тырышлык таләп итә. Ул эшләгән дәвердә приют республика күләмендә алдынгы урыннарны били. Балалар саны тулы, аларга күрсәтелгән хезмәт югары дәрәҗәдә алып барыла. Иске бинада урнашкан приютны, кыска вакытларда санитар таләпләргә җавап бирерлек, пожар куркынычсызлыгы кагыйдәләрен төгәл үтәрлек шартлар тудыра ул. Приютта тәрбия алып төрле җирләрдә яшәүче балалар белән хәзер дә хәбәрдә торуы аның хезмәтенә иң зур бәя. "Аллага шөкер, аларның күпчелеге үзләре дә әти-әни инде. Тормышлары да төрлечә. Киңәш сорап мөрәҗәгать итүләренә дә сөенәм," - дип хисләрен бүлешә апалары.

2009 нчы ел яңадан тормышына үзгәреш кертә. Район администрациясе аңа балалары белем алган мәктәпне җитәкләргә тәкъдим итә. Мәктәптә урнашкан туалетның бер дә чистартылмавы, санитар таләпләргә туры килмәве сәбәпле, мәктәптә уку башларга рөхсәт тә бирми Мәктәпләрне яңа уку елына кабул итү комиссиясе. Кабул иткән коллектив фән ияләре җитешмәү, җылылык һәм су трассаларында өзеклекләр, укучыларның 37 % ы тәрбиягә алынган, опекунлыкта һәм приютта тәрбияләнүчеләр белән каршы ала аны. Шул елны туалет заман таләпләренә туры килерлек итеп ремонтлана. Яңа су трассасы салына. Коллектив белән белем һәм тәрбия бирүгә максат куеп, аңа ирешү юллары сайлана.

2010 ел мәктәпләргә ФДББС (ФГОС) кертү чоры. Яңалыкны өйрәнү күпме өстәмә уку, тырышлык, төгәллек таләп итә. Законнарга нигезләнеп эш оештыру, коллективның бердәм ярдәмләшеп эшләве бу этапны үтүдә мөһим роль уйный. ФДББС уку хезмәтен социаль институтлар белән хезмәттәшлектә оештыруны таләп итә. Бу юнәлештә дә эшчәнлек үз югарылыгына куела. Мәктәпнең уңай эш тәҗрибәсен өйрәнү һәм җирлегебездә куллану максатында, эшчәнлек авыл җирлеге сессиясендә, муниципаль район советының киңәйтелгән утырышында, балигъ булмаган балалар комиссиясе утырышларында, укытучыларның республикакүләм август киңәшмәсендә өйрәнелде.

2012 нче елда мәктәпкә күптән көтелгән ремонт керә. Бу чорда коллектив зур оешканлык күрсәтә. Көнне төнгә ялгап, ремонт эшләрен уку елы башлануга төгәлләүгә ирешә. Районга эшлекле сәфәр белән килгән Татарстан Республикасы презединты Рөстәм Нургалиевич Минеханов мәктәптә булып, эш сыйфатынан канәгатьлеген әйтте.

Тынгысыз җитәкче, 2014 нче елда, “Бердәм Россия” партиясе һәм Татарсан Республикасы хөкүмәте тарафыннан оештырылган социаль проектлар конкурсына катнашып лауриат була. 580 мең сумга мәктәпкә хоккей коробкасы кайтартуга ирешә.

2018 нче елда мәктәпләрнең яңа уку елына әзерлеге буенча 200 меңлек сертификатка ия була.

2019 нчы елдан Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбе Россия мәгариф академиясе мәгарифне үстерү стратегиясе институтының “Үрнәк тәрбия программасын апробацияләү” тәҗрибә мәйданчыгында эш алып бара башлады. Экспериментның төп максаты: һәр мәктәпнең үзендә җирлек үзенчәлекләрен һәм балалар контенгентын исәпкә алып тәрбия эшчәнлеген оештыру.

2020 нче елда мәктәп республика күләмендә тагын ике җиңүгә иреште.

Гомумән, ул эшләгән чорда укытучылар белән дә, ата-аналар белән дә, укучылар белән дә һәрьяклап заман таләпләренә туры китереп эш оештырылды. Укытучыларның квалификацион категориясен күтәрүгә зур әһәмият бирелде. Бүгенге көндә коллективның үсешкә йөз тотып эшләвендә Ләйсинә Расиловнаның өлеше, һичшиксез, зур.



## Каримова Миләүшә Мирзанур кызы

1999 нчы елда Алабуга дәүләт педагогия институтын тэмамлап, Мөслим районы Мәллэтамак авылында инглиз теле укытучысы булып эшли башлый. 2013 нче елда Казан федераль университетында менеджмент белгечлеге ала. 2001 нче елда гаилә кору сәбәпле, Кубәк урта гомуми белем биру мәктәбенә инглиз теле укытучысы булып күчә. Җәмәгать эшләрендә бик актив катнаша. 2009 нчы елдан хәзерге көнгәчә укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып хезмәт куя.

Миләүшә Мирзануровна җаваплы, таләпчән, төгәл белгеч булып танылды.

2020 нче елда укучыларга белем һәм тәрбия бирүдә куйган хезмәтләре Мөслим муниципаль районы Мәгариф идарәсенең мактау грамотасы белән билгеләп үтелде. Укытучының инглиз теле буенча фән олимпиадасының муниципаль этабында призер укучылары булуы да куанычлы нәтиҗә.

Миләүшә Мирзанур кызы  инглиз телендә укучыларын дөрес укырга һәм язарга, матур итеп үз фикерен җиткерергә, яхшылыкны күңеленә сеңдерергә, тормышны аңларга, аны яратырга өйрәтә, чын күңелдән аларның уңышына шатлана һәм горурлана. Гомерен балаларга багышлаган, аларны киләчәк  тормышка әзерләүгә алынган, шушы мактаулы эшкә бар күнелен, йөрәк җылысын салган тынгысыз, көчле рухлы мөгаллим.



## Гарифуллина Дилбәр Рафак кызы

1972 нче елның 10 нчы сентябрендә Мөслим районы Бәкәбез авылында туа. Бала чагы гүзәл табигатьле авылы кочагында уза аның. Башлангыч белемне авылдагы башлангыч мәктәптә ала. Әмәкәй урта мәктәбен тәмамлагач, юллары Дилбәр Рафаковнаны Алабуга дәүләт педагогия институтына китерә. Ул тарих-филология факультетына укырга керә. 1996 нчы елның 24 нче июнендә кулына “Татар теле һәм әдәбияты укытучысы” дипломын ала. Өстәмә курслар узып (профессинальная переподготовка), “Рус теле һәм әдәбияты укытучысы” белгечлегенә ия була.

Тәүге хезмәт юлын 1992 нче елда Мөслим районы Октябрь урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак башлый. 2014 нче елга кадәр хезмәте шушы мәктәп белән бәйле.

2014-2015 нче уку елында Уразмәт төп мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбияты укыта. Шул ук вакытта тәрбия эшләре буенча директор урынбасары вазифаларын башкара. Укытучы белгечлеге буенча югары квалификацион категорияне яклый.

2015-2016 нчы уку елыннан Дилбәр Рафаковнаны Күбәк урта мәктәбенә татар теле һәм әдәбияты укытучысы, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары итеп билгелиләр. Хәзерге көнгә кадәр ул шушы мәктәптә хезмәт куя.

Гарифуллина Д.Р.ның укучылары - күп санлы халыкара, бөтенрәсәй, республика һәм региональ фәнни-гамәли конференция, татар теле һәм әдәбияты буенча фән олимпиадаларының республика, муниципаль этаплары җиңүчеләре һәм призёрлары. Конкурсларда да аның укучыларына тиңнәр юк.

Гарифуллина Д.Р. - инновацион практик. Ул һәрвакыт яңа эш алымнары, алдынгы тәҗрибә белән уртаклаша. Эксперт буларак, конференцияләрдә, олимпиадаларда жюри составында. Аның ачык дәресләре, мастер-класслары һәрвакыт югары бәяләнә.

2019-2020 нче уку елында Күбәк урта мәктәбе Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы заказы буенча эшләнгән үрнәк тәрбия

программасын гамәлгә кертүдә Идел буе округы буенча тәҗрибә мәйданчыгы булып тора. Бу – Дилбәр Рафаковнаның тырыш хезмәте нәтиҗәсе.

Һөнәри яктан компетентлы, методик яктан грамоталы оста педагог-2014 нче елда “Безнең иң яхшы укытучы" гранты, 2020 нче елда "Татар телендә укытуны гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләргә ярдәм” гранты җиңүчесе, 2016 нчы елда "Иң яхшы интернет-педагог" Бөтенрәсәй педагогик конкурс-квестында "Гомуми белем бирүдә иң яхшы IT-педагог" номинациясе”ндә җиңүче, 2018 нче елда «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» Бөтенрәсәй бәйгесендә III урын иясе.

Намуслы һәм тырыш хезмәте өчен Дилбәр Рафаковна түбәндәге бүләкләргә ия:Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы, 2018 елның 24 августы.Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы, 2020 елның 13 феврале.



## Нуруллина Эльмира Мәхмүт кызы

1971 нче елның 19 нчы маенда туган. Кеше һөнәрне үзе сайлап ала диләр. Ә Эльмира Мәхмүтовна һөнәр үзиясен үзе эзләп таба дияр иде, чөнки рус теле һәм әдәбияты укытучысы Шәмсиахметова Рәзимә апаны чиксез яратуы, хөрмәт итүе, аны КДПИ на китерде.1988 нче елда рус филологиясе факультетында укый башлый, 1993 нче елда уку йортын уңышлы тәмамлап, гаиләсе белән Иске Карамалы авылына яшәргә кайта. 1994 нче елда Күбәк урта мәктәбендә килә. Хезмәт юлын башлангыч класс укытучысы булып башлый. Ике елдан соң рус теле һәм әдәбияты дәресләрен укытуга күчә. Шулай ук 4 ел тәрбия эшләре буенча урынбасар вазифасын башкара. 27 ел укучыларга белем һәм тәрбия бирә. “Бу һөнәрне үзләштергәнемә һич үкенмим, үземне бәхетле дип саныйм,” - ди Эльмира Мәхмүтовна.

Эшенең асылына килгәндә, ул балаларны уку хезмәтенә күнектерүне үз алдына максат итеп куя. Бу, билгеле, дәвамлы хезмәт сорый. Бала, уку хезмәтенең нәтиҗәсе - белемле булу икәнлеген, белемнең кирәк булуын аңламаса, үз-үзенә билгеле максат куя алмый. Ә белем һәм тәрбия бирү – бу эшчәнлекнең аерылгысыз тармаклары. Моның өчен үз алдына шундый таләпләр куя: балаларны чын күңеле белән ярату, аларда үз балаларының чагылышын күрү, һәр дәресне ныклы әзерлек белән үткәрү, эшенә даими анализ.

Рус теле һәм әдәбияты укытучыларынааеруча зур җаваплылык йөкләнгән. Чөнки баланың киләчәге имтиханнарны ничек бирүенә бәйле. Биргән белемнәрен, үгет-нәсихәтләрен балаларга тиз, аңлаешлы барып җитсен өчен, һәр дәресенә, һәр үздырган чарасына ныклап әзерләнергә тырыша. Укучыларынын төрле конкурсларда, олимпиадаларда алган урыннары өчен чын күңелдән куана. Дистәдән артык укучылары бердәм дәүләт имтиханнарында югары баллар җыеп, укуларын дәвам итәләр. Аларның уңышларында Эльмира Мәхмүтовнаның дә өлеше бик зур.

“Бала күңеле - чиста ак кәгазь. Аңа нинди бизәк төшерсәң – ул шуны саклый. Үзенә белем Һәм тәрбия биргән укытучылары турында да аның күңел дәфтәрендә урын бар. Әлеге дәфтәрдә минем исемем дә бар икән, димәк минем хезмәтем кирәк булган”,- ди Эльмира Мәхмүтовна.



# Гараева Рузилә Нияз кызы

1993 нче елда Яр Чаллы дәүләт педагогия институтының “Башлангыч белем бирүнең педагогикасы һәм методикасы” бүлеген тәмамлый. Хезмәт юлын Үрәзмәт урта гомуми белем бирү мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып башлап җибәрә.

Гаилә хәле буенча, 1996 нчы елдан Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбендә эшли башлый. 1996-2003 нче елларда география фәнен укыта. 2003 нче елдан бүгенге көнгә кадәр башлангыч сыйныфларда белем бирә.

21 нче гасыр укытучысыннан педагогик культура һәм педагогик фикер йөртү таләп ителә. Шуны истә тотып, Рузилә Ниязовна дәресләрдә интернет ресурслардан киң файдалана, укучылар белән берлектә аларның эзләнү-тикшеренү эшчәнлеген оештыра. Дәресләрендә индивидуаль һәм дифференциаль укытуга аерым игътибар итә. “Әлбәттә, замана күзлегеннән чыгып карагандa һөнәрем җиңел түгел, ләкин үз эшеңне яратып башкарсаң, һәр иртәдә ашкынып мәктәпкә килсәң, балаларның зур ышаныч белән сиңа төбәлгән карашларын күрсәң, күңелеңне хезмәтеңнән канәгатьләнү тойгысы, шатлык хисләре чолгап ала,”- дип уртаклаша укытучы.

Укытучылык – Рузилә Нияз кызының яшәү мәгънәсе. Ул яңалыкка омтылучы, заман сулышын тоючы, белемен өзлексез камилләштерүче, укыту-тәрбия эшенә иҗади якын килүче, яңа заман технологияләре белән бергә атлаучы укытучы, компетентлы белгеч. Һөнәри осталыгын камилләштерү өстендә даими эшли.2010 нчы елдан Күбәк куст-методик берләшмә җитәкчесе, 2014 нче елдан – югары категорияле укытучы. “Сыйныф җитәкчесе – 2012” конкурсында “Иң яхшы сыйныф җитәкчесе” номинациясендә, “Ел укытучысы – 2015” конкурсында “Башлангыч сыйныф укытучысы” номинациясендә җиңүче, 2017 нче елда “Оста мөгаллим” грантына ия була.



# Шәяхмәтова Ләйсән Фидаел кызы

1977 нче елның 26 нчы июнендә Мөслим районы Октябрь авылында туа.1994-1997 елларда Минзәлә педагогия көллиятен тәмамлый. 2008-2011 елларда Яр Чаллы педагогия институтының (НГПИ) "Башлангыч белем бирүнең педагогикасы һәм методикасы" бүлегендә читтән торып югары белем ала.

Мәгариф өлкәсендә эшчәнлеген 1997 нче елда Мөслим районы Исәнсеф-Чишмә башлангыч мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып башлап җибәрә. 1999-2003 елларда Түбән Кама шәһәренең 43 нче балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. 2003- 2006 нчы елларда Октябрь урта гомуми белем бирү мәктәбендә башлангыч сыйныфларда укыта.

2006 нчы елдан бүгенге көнгә хатле Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшли. Күп еллар мәктәптә укыту дәверендә, укучыларына төпле белем бирергә тырыша, тормышта үз юлларын таба белүче, олыларны хөрмәт итүче чын кешеләр итеп тәрбияләргә омтыла.

Ләйсән Фидаел кызы яңа заман технологияләре белән бергә атлаучы укытучы. Һәр эшне намус белән, җиренә җиткереп башкара белә. Бәйрәм һәм чараларны татар телендә уздыра. Телне саклау, үстерү һәм киләчәк буынга җиткерү өчен үзеннән өлеш кертә. Укучылары фән бәйгеләрендә, фәнни- гамәли конференцияләрдә даими катнашып, матур нәтиҗәләр күрсәтәләр.

Өзлексез үз белемен һәм гамәли күнекмәләрен күтәрү өстендә эшли. 2003 нче елдан – беренче категорияле укытучы. "Ел укытучысы", "Ел класс җитәкчесе" конкурсларында катнашып мактау кәгазьләренә лаек. Ләйсән Фидаел кызы укучыларының яраткан сыйныф җитәкчесе дә.Укучылары башлангычны тәмамлап чыгып китсәләр дә, беренче укытучылары белән һәрдаим элемтәдә.



## Юсупова Ландыш Мирзаян кызы


2010 нчы елдан Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбендә башлангыч классլар укытучысы булып эшли башлый.

Йомшак, матур тавышы, кешеләр белән елмаеп кына сөйләшүе, ягымлы карашы, һәрвакыт акыллы киңәшләр бирүе белән ул балаларда тормышны, кешеләрне ярату, җәмгыятькә файдалы шәхес булып үсү теләге уята.

Кечкенәдән үк эшкә өйрәтеп, хезмәткә мәхәббәт тәрбияләп үстергәннәре өчен әти-әнисенә чиксез рәхмәтле ул. Балачактан ук укытучы һөнәренә гашыйк була, мәктәпне тәмамлагач, хыялын чынга ашыра: башта Минзәлә дәүләт педагогия көллиятендә башлангыч класслар укытучысы бүлегендә укый, ә аннары читтән торып Яр Чаллы дәүләт педагогия институтын тәмамлый.

Үз эшен бик яратып, җиренә җиткереп башкара ул. Гомерен мәгарифкә багышлаган кеше буларак, Ландыш Мирзаяновна дәресләрен кызыклы, мавыктыргыч итеп үткәрергә тырыша.

Белем бирү өлкәсендәге тырыш хезмәте өчен Ландыш Мирзаяновна район мәгариф бүлегенең, Мәгариф һәм фән министрлыгының Рәхмәт хатлары белән бүләкләнде.



## Нәҗмиева Гөлнар Ленар кызы

2000 нче елның август аеннан татар теле һәм әдәбияты укытучысы вазифасын башкара.

Намуслы һәм тырыш хезмәте өчен Гөлнар Ленар кызы түбәндәге бүләкләргә ия булды:

-Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафынантатар әдәбиятыннан Республика олимпиадасының йомгаклау этабында призер әзерләгән өчен Грамота 2019, 2020 нче еллар;

- Мөслим муниципаль районы Мәгариф идарәсе тарафыннан татар телеһәм әдәбиятыннан Республика олимпиадасының муниципаль этабында җиңүчеләр һәм призерлар әзерләгән өчен Мактау грамоталары 2015-20 нче еллар;

- Мөслим муниципаль район башлыгының Рәхмәт хаты 2019;

- “Татарстан Республикасы Идел буе халыкларының туган телләрен өйрәнү һәм укыту: тарих һәм хәзерге заман” конференциясе, диплом, 2018;

- Республикакүләм Ризаэддин Фәхреддин укулары, 1 дәрәҗә диплом, 2017, 2019;

- “Кадыйр Сибгатуллин исемендәге I Республика фәнни гамәли конференция”, 2 дәрәҗә диплом, 2019.

Гөлнар Ленар кызы мәктәптә эшләү дәверендә үзен укучыларны кызыксындырырга сәләтле, тирән белемле укытучы буларак танытты. Укытучының һөнәри осталыгы укучылар, аларның ата-аналары һәм мәктәп җитәкчелеге тарафыннан югары бәяләнә. Г.Л.Нәҗмиеваның укучылары төрле дәрәҗәдәге олимпиада, конкурсларда теләп катнашалар һәм призлы урыннар яулыйлар:

- Кояш Тимбикова исемендәге II регионара фәнни-эзләнү укуларында - призер;

- "Глобальләшү – хәзерге заман чынбарлыгы" XI гуманитар фәнни-гамәли конференциясе – 3 нче дәрәҗә диплом;

- Мәктәп укучыларының Ярослав Гашек исемендәге «Яшь филолог» филологик фәнни-гамәли конференциясе – 2 нче дәрәҗә диплом;

- “РФ халыклары телләрре” мәктәп укучыларының фәнни-гамәли конференциясе һәм укулары (Научно-практическая конференция и чтения школьников на языках народов РФ) диплом;
- “Шушы яктан, шушы туфрактан без” фәнни-гамәли конференция - лауреат;
- “Фаот Садриев укулары " фәнни-гамәли конференция 2016-19 еллар, сертификат, 2, 3 нче дәрәҗә диплом.
- 2016-2017 татар теле һәм әдәбиятыннан Республика олимпиадасының муниципаль этабында – 2 призер;
- 2017-2018 татар теле һәм әдәбиятыннан Республика олимпиадасының муниципаль этабында – 1 җиңүче, 2 призер;
- 2018-2019 татар теле һәм әдәбиятыннан Республика олимпиадасының муниципаль этабында – 1 җиңүче, 2 призер, 1 – республикакүләм призер;
- 2019-2020 татар теле һәм әдәбиятыннан Республика олимпиадасының муниципаль этабында – 3 җиңүче, 4 призер, 1 – республикакүләм призер.
- 2020-2021 татар теле һәм әдәбиятыннан Республика олимпиадасының муниципаль этабында – 2 җиңүче, 4 призер.

Гөлнар Ленар кызы үз хезмәтендә ИКТ, заманча педагогик технологияләрне оста кулланып, һәр балага шәхси якын килеп, аларның мөмкинлекләрен камилләштерергә омтыла. Дәресләрендә укучыларга тормышта бик кирәк булган аралаша белү, хезмәттәшлек итү, анализлау, тәнкыйди фикерләү күнекмәләрен үстерүгә зур игътибар бирә.

Мөгаллимә даими эзләнә, үзе дә республикакүләм фәнни-гамәли конференцияләрдә катнаша, призлы урыннар яулый.

Нәҗмиева Г.Л. мәктәп, район укытучылары өчен ачык дәресләр, мастер-класслар күрсәтә; семинарларда, педагогик киңәшмәләрдә, методик берләшмә утырышларында чыгышлар ясый, үз тәҗрибәсе белән уртаклаша.



# Шангараева Алисә кызы

1993 елның 22 нче августында Мөслим районының Яңа Сәет авылында туа. Урта белемне Мари-Бүләр авылында алып чыга. 2011 елның Яр Чаллы дәүләт педагогия институтының “Башлангыч белем бирүнең педагогикасы һәм методикасы” факультетына укырга керә.

Үзенең хезмәт юлын 2015 елда Күбәк урта гомуми белем бирә мәктәбендә башлый. 2019 нчы елга беренче категориягә ия була.

Үзенең дәресләрендә укучыларда кызыксыну уяту өчен, заманча технологияләрдән файдалана. Бүгенге көндә интернет аша күп мәгълүмат алырга өйрәнгән замана балаларын кызыксындыру өчен, зур тырышлык куеп эшли. Туган илен, телен яратучы, үз милләтенең тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, күркәм йолаларын хөрмәт итүче укучылар тәрбияләүне максат итеп куя.



# Фәхртдинова Дилбәр Нәкыйф кызы

1968 нче елның 12 нче октябрендә Мөслим районы Метрәй авылында туган. 1991 нче елда Казан дәүләт педагогия институтының физика-математика факультетының математика, информатика һәм исәпләүләр техникасы бүлеген тәмамлап, Мөслим районының Октябрь урта мәктәбенә эшкә кайта. Анда 7 ел математика укытканнан соң хезмәт юлын Метрәй урта мәктәбендә дәвам итә. 2015 нче елда Метрәй төп гомуми белем бирү мәктәбе башлангыч мәктәпкә әйләнә. Һәм ул 2015-16 нче уку елында Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбенә укытырга килә.

Күп еллар мәктәптә математика укыту дәверендә, укучыларына төпле белем бирергә, тормышта үз юлларын таба белүче, олыларны хөрмәт итүче чын кешеләр итеп тәрбияләргә омтыла. Намуслы һәм тырыш хезмәте өчен Дилбәр Нәкыйфовна, Мөслим муниципаль районы Мәгариф идарәсенең математика фәненнән Республика олимпиадасының муниципаль этабында призерлар әзерләгән һәм педагогик эшчәнлегендә югары дәрәҗәләргә ирешкән өчен Мактау грамоталары белән бүләкләнде.

2017 нче елда “Өлкән укытучы” гранты иясе. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының “Мәгариф” журналы белән берлектә уздырылган Бөтенроссия “Авыл укытучысы” конкурсында 2016 нчы елда, “Предметка мәхәббәт” номинациясендә, ә 2020 нче елда “ Җиңүгә омтылыш” номинацияләрендә җиңүче.

Дилбәр Нәкыйфовна үз хезмәтендә ИКТ, заманча педагогик технологияләрне оста кулланып, һәр балага шәхси якын килеп, аларның мөмкинлекләрен камилләштерергә омтыла. Дәресләрендә укучыларга алган белемнәрен тормышта куллана белүгә, хезмәттәшлек итү, анализлау, тәнкыйди фикерләү күнекмәләрен үстерүгә зур игътибар бирә.

Фәхртдинова Д.Н. мәктәп, район укытучылары өчен ачык дәресләр, мастер-класслар күрсәтә, семинарларда, педагогик киңәшмәләрдә, методик берләшмә утырышларында чыгышлар ясый, үз тәҗрибәсе белән уртаклаша.



# Нурлыгаянова Фирая Мирзанур кызы

1972 нче елның 17 нче апрелендә табигатьнең гаҗәеп гүзәл бер почмагы булган Мөслим районы Краснояр авылында туган. 1979 нчы елның 1 сентябрендә укырга кереп, гөлбакчадай матур кечкенә авылның башлангыч мәктәбендә белем ала. Өч ел туган авылында белем алгач, урта мәктәпкә Симәк авылына йөреп укый башлый.

1989 нчы елда Симәк урта мәктәбен яхшы билгеләргә генә тәмамлый. Елга-күлләргә, урман-болыннарга бай авылда үскән кыз буларак, Алабуга дәүләт педагогика институтының биолоия факультетына укырга керә. 1994 нче елда аны тәмамлап, хезмәт юлын Баланлы урта мәктәбендә химия һәм биология укыутчысы буларак башлап җибәрә. 1996 нчы елдан Күбәк урта мәктәбендә химия һәм биология укытучысы булып эшли. Тормыш иптәше Наил белән гаиләдә 3 кыз тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге вакытта кызлары Фирүзә һәм Илүзә югары уку йортында белем алалар. Кече кызлары Ралинә 3нче сыйныфта укый.

Фирая Мирзануровна укучыларга авыр, ләкин мавыктыргыч химия, биологиядән теоретик һәм практик белем биреп, фәннәрнең нигезләрен үзләштерергә ярдәм итә. Укытуның төрле методларын кулланып уздырган дәрес һәм дәрестән тыш чаралары кызыклы да, файдалы да уза. Озак еллар укытучы, класс җитәкчесе булып эшләү дәверендә, укучыларда шәфкатлелек, намуслылык, изгелек, табигатьне, туган ягыбызны ярату, кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләүдә үзеннән зур өлеш кертә. Тормышта үз юлларын табып, шәфкать туташлары, врачлар, психологлар,нефтьчеләр, авыл хуҗалыгы белгечләре булып эшләүче укучыларының хезмәт нәтиҗәләрен күреп горурлана. Шулай ук төрле уку йортларында укучы кичәге укучыларына да уңышлар теләп кала.



## Вәлиева Гөлнара Әзһәри кызы

1970 нче елның 15 нче мартында Мөслим районы Иске Карамалы авылында эшче гаиләсендә дөньяга килә. 1977-1987 нче елларда Мөслим районы Күбәк урта мәктәбендә белем ала. Мәктәпне тәмамлагач, Түбән Кама шәһәренең 66 нчы махсус һөнәри-техник училищесында укый. Аны кызыл диплом белән тәмамлап, Түбән Кама шин заводында лаборант булып эшли башлый.

1990 нчы елда туган авылына кайта.

1993-1998 нче елларда Яр Чаллы дәүләт педагогия институтының нәфис графика бүлегендә белем ала.

1998-1999 нчы уку елында Мөслим районының 2 нче номерлы урта мәктәбендә рәсем сәнгате укытучысы булып эшли. 1999-2001нче елларда Мөслим районының Баек авылы балалар бакчасында тәрбияче булып хезмәт юлын дәвам итә. 2001 нче елдан Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбендә педагог-оештыручы һәм рәсем сәнгате укытучысы булып эшли. Ул 2010 нчы елдан алып мәктәпнең Яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядын да җитәкли.

Гөлнара Әзһәри кызы хезмәтен яратып, җиренә җиткереп башкара. Аның укучылары район һәм республикакүләм конкурсларда, олимпиадаларда катнашып призлы урыннар алалар. Гөлнара Әзһәри кызы видеофильмнар төшерү белән дә шөгыльләнә. Укучылар белән кыска фильмнар төшереп, республикакүләм үткәрелгән "Унынчы муза" яшь кинематографистлар конкурсында һәм «Милли мультFest» балалар кинофестивалендә катнаштылар.



# Низамова Диләрә Нурислам кызы

1982 нче елның 10 нчы гыйнварында Татарстан Республикасы Казан шәһәрендә гаиләдә икенче бала булып дөньяга килә. Ул хезмәт сөючән, тәртипле гаиләдә үсә.

1989 нчы елда Казан шәһәренең 81 нче урта мәктәбенә татар сыйныфына укырга керә. 1999 нчы елда мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан шәһәренең 21 нче санлы көллиятендә хисапчы һөнәрен үзләштерә.

2001 нче елда язмыш җилләре аны Мөслим районы белән бәйли. Яңа Карамалы авылына килен булып төшә.

2003 нче елда читтән торып Яр Чаллы шәһәренең югары белем бирү педагогия институтына рәсем сәнгате факультетына укырга керә. 2008 нче елда уңышлы гына аны тәмамлый.

Педагогик эшчәнлеген 2006 нчы елда Мөслим районы Иске Карамалы авылында урнашкан яшүсмерләр һәм балигъ булмаган балалар өчен “Наз” социаль приютында башлап җибәрә. 2006-2014 нче елларда социаль педагог вазифаларын башкара, шуның белән беррәттән 2009-2012 нче елларда Күбәк урта мәктәбендә технология дәресләрен укыта.

2016 нчы елдан алып бүгенге көнгә кадәр Күбәк урта мәктәбендә кызларга технология фәнен укыта һәм мәктәп китапханәсен җитәкли.

Укытучының хезмәте үз укучыларының иҗади эшчәнлегендә чагылыш таба. Укучылары районкүләм олимпиадаларында, республика күләм иҗади конкурсларда, фәнни конференцияләрдә катнашып, призлы урыннар яулыйлар.

Белем бирү өлкәсендәге тырыш хезмәте өчен 2020 нче елда Диләрә Нурисламовна район мәгариф бүлегенең грамотасы белән бүләкләнде.



## Ханнанов Флорес Габделҗәмил улы

1973 нче елның 9 нчы сентябрендә Татарстан Республикасы Мөслим районы Октябрь авылында биш балалы гаиләдә дүртенче бала булып туган.

1981 нче елда Октябрь урта мәктәбенә укырга кергән, 1991 нче елда тәмамлаган. 1991-1993 нче елларда Совет армиясе сафларында хезмәт иткән. Хезмәт юлын Ракета гаскәрләрендә Белоруссиядә, Архангельскийда, Мари Илендә һәм Киров өлкәсендә үткән.

1994 нче елда Әлмәт физик культура техникумына укырга кергән, аны 1996 нчы елда тәмамлаган.

1996 нчы елда Мөслим районы Баек урта мәктәбенэ физик тәрбия укытучысы булып кайта.

2001 нче елдан Күбәк урта мәктәбендә тормыш иминлеге нигезләре һәм физик культура укытучысы булып эшли.

Иптәше белән 1 малай 2 кыз үстерәләр. Хәзерге вакытта өлкән улы Әлмәт физкультура колледжында белем ала. Олы кызы мәктәптә, кече кызы балалар бакчасында. Флорес Габделҗәмилович гаиләдә үрнәк эти, эшендә җаваплы хезмәткәр.

Тырыш хезмәте мәгариф идарәсенең күпсанлы мактау кәгазләре белән билгеләп үтелде, 2020 нче елда район администрациясе башлыгының Мактау грамотасына лаек булды.



# Валиуллина Әлфинә Мирзариф кызы

1969 нчы елның 7 нче гыйнварenda Мөслим районы Иске Сәет авылында туа.

1976 нчы елда Иске Сәет башлангыч мәктәбенә укырга керә. 1986 нчы елда Татар Буләре урта мәктәбен яхшы билгеләргә тәмамлап, Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә. Анда ул физика-математика факультетында белем ала, укытучы һөнәрен үзләштерә. 1992 нче елда институтны уңышлы тәмамлап, математика укытучысы булып эшли башлый.

1999-2014 нче елларда Октябрь төп гомуми белем бирү мәктәбендә математика, физика фәннәрен укыта, укыту эшләре буенча директор урынбасары вазифасын башкара. 2017 нче елдан Күбәк урта мәктәбендә математика, физика укытучысы булып эшли башлый һәм бүгенге көндә дә шушы мәктәптә хезмәт куя.

Әлфинә Мирзариф кызы укучыларга тирәнтен белем бирүне, математика, физика фәннәренә кызыксыну уятуны максат итеп куя. Беренче категорияле укытучы буларак, ул район күләм оештырылган семинарларда ачык дәресләр бирә, математика укытуга кагылышлы темаларга чыгышлар ясый. Уз эшен чын күңеленнән яратып башкара Әлфинә Мирзариф кызы.



## Шаймөхәммәтов Илназ Хәлил улы

Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбендә 2017 нче елдан тарих һәм җәмгыять белеме укытучы булып эшли.

Илназ Хәлил улы Азнакай районы Чалпы авылында эшчеләр гаиләсендә дөньяга килә.Чалпы урта мәктәбендә белем ала.

2012-2017 нче елларда Алабуга дәүләт педагогия институтының татар һәм чагыштырма филология бүлегендә белем ала. Хезмәт юлын 2017 нче елдан Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбендә тарих һәм җәмгыять белеме укытучы буларак башлап җибәрә. 2017 елда, Күбәк мәктәбендә 3 ай эшләгәннән соң, армия сафларына алына, хәрби бурычны үтәп кайткач, янә Күбәк урта мәктәбендә яраткан эшен дәвам итә.

Эшлекле, тырыш белгечне бердәм дәүләт имтиханына елда оештыручы итеп куялар һәм ул үз эшен җаваплылык белән башкара. Өзлексез үз белемен һәм гамәли күнекмәләрен үстерү өстендә эшли. Республикакүләм һәм муниципаль семинарларда актив катнаша һәм бу үзенең нәтиҗәләрен бирә. Илназ Хәлил улының укучылары бердәм дәүләт имтиханнарында ел да уңышлы тапшыралар.



## Гайров Ильяс Зинур улы

1987 нче елда Шумерля шәһәрендә дөньяга килә. 1994 нче елда Әлмәтнең егерменче урта мәктәбенә укырга керә һәм 2004 нче елда аны уңышлы төгәлли.

2008 елда Әлмәтнең физик культура техникумын тәмамлый. 2010 елда хезмәт юлын Күбәк урта белем бирү мәктәбендә башлап җибәрә. Югары белем алу өчен Яр Чаллы педогогия институтының физик тәрбия факультетына укырга керә. 2017 нче елда кулына диплом ала.

Бүгенге көндә Күбәк урта белем бирү мәктәбендә хезмәтен дәвам итә.



## Солтанова Гөлнара Роберт кызы

1977 нче елның 2 нче маенда Татарстан Республикасы Сарман районы Җәлил эшчеләр бистәсендә туа. 1994 нче елда Җәлил бистәсенең 2 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбен яхшы билгеләренә тәмамлап, Алабуга дәүләт педагогия институтының филология факультетына укырга керә. 1999 нчы елда югары белемле татар теле һәм әдәбияты, инглиз теле укытучысы белгечлеге алган, Гөлнара Роберт кызы хезмәт юлын Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәренең 11 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбендә инглиз теле укытучысы буларак башлап җибәрә.

2000 нче елдан 2013 нче елга кадәр Әлмәт шәһәренең Риза Фәхретдин исемендәге татар гимназиясендә инглиз теле укытучысы буларак хезмәтен дәвам итә. 2013 нче елдан Татарстан Республикасы Мөслим районы Баек төп гомуми белем бирү мәктәбенең Дусай башлангыч мәктәбе филиалында һәм Октябрь төп гомуми белем бирү мәктәпләрендә инглиз теле укытучысы булып эшли башлый. 2018 нче елда Баек төп гомуми белем бирү мәктәбендә тәрбия эшләре буенча директор урынбасары һәм инглиз теле укытучысы булып эшли. 2019 нчы елда Баек төп гомуми белем бирү мәктәбенә директор булып билгеләнә.

Күп еллар мәктәпләрдә чит телләр укыту дәверендә укучыларына төпле белем бирергә тырыша, тормышта үз юлларын таба белүче, олыларны хөрмәт итүче чын кешеләр итеп тәрбияләргә омтыла. Укучылары республика олимпиадаларының район турларында, район һәм республика күләмендә үткәрелгән конкурсларда актив катнашалар.

Бүгенге көндә педагогик эшчәнлеген Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбендә чит телләр укытучысы буларак дәвам итә.



## Разиля Канафиевна Фаррухшина

1964 нче елда Мөслим районының Баек авылында туган. Туган авылында 8 класс белем алгач, Минзәлә шәһәрендәге педагогия училищесында укый. Кулга башлангыч класслар укытучы турындагы документ алгач, туган мәктәбенә кайта. Югары белем алу теләге көчле була, шул елны ук Казан дәүләт университетына юнәлә. Анда 6 ел дәвамында читтән торып, рус теле һәм әдәбияты факультетында укый.

Хезмәт юлын Баек урта мәктәбендә башлаганнан соң, башлангыч классларда урын булмау сәбәпле, география дәресләре укыта башлый. Төрле бәйрәм чаралары белән аралаштырып барган укыту процессы аңа бик ошый. Ул оештырган бию группасының чыгышлары район күләмендә оештырылган конкурста җиңеп чыккач, Разиля Канафиевнаны Мөслим урта мәктәбенә укытырга чакыралар. Ул вакытта Мөслимдә бер генә мәктәп була. Анда рус теле һәм әдәбияты укыта, шунда ук өлкән укытучы категориясе ала.

1998 елда "Авыл утлары" газетасы хезмәткәрләре белән очрашу була, редактор: "Безгә журналистлар җитми", дигән сүзне әйтә, һәм Разиля Канафиевна шунда күчәргә дигән нияткә килә. Анда да бик яратып хезмәт куя. Радио, телевидение, газетада эшләү тормыш тәҗрибәсен баетуда, кешеләр белән аралашу, танышуда, әйләнә-тирәгә, дөньяга карашны үзгәртүдә зур роль уйнады, - ди Разиля Канафиевна.

9 елдан соң үзен башка өлкәдә сынап карарга тели. Ул вакытта сетевой бизнес "кузгалып килә", ул шул дулкынга кушыла . Ул еллар – аның тормыш мәктәбе булды, дисәм, дөрес сүзләр булыр, дип искә ала Разиля Канафиевна. Кызыклы шәхесләр белән очрашу, рухи үсеш буенча китаплар уку файдалы булды, күп шәһәрләрдә булдым, семинарларда, форумнарда катнаштым, ди.

2011 елда аны кабат "Авыл утлары" редакциясенә редактор урынбасары буларак эшкә чакыралар. Журналистика Разиля Канафиевнаның бик яраткан өлкә булса да, бер елдан бу тармактан китәргә туры килә.

Аннан аңа Укучылар белән эшләү үзәгендә методист булып эшләргә тәкъдим итәләр.

2020 елның 1 сентябрендә Күбәк урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты дәресләре укыта башлый.22 ел дәвамында педагогика өлкәсеннән читтә торганнан соң,мәктәп системасына килеп кушылу – минем өчен бәйрәм кебек булды,- ди Разиля Канафиевна. Балалар белән эшләү – бик күңелле, хәзер мин Сухомлинскийның “Йөрәгемне балаларга бирәм” дигән сүзләрен бик яхшы аңлыйм, - дип бүлешә ул.

Иң мөһиме – җан җылысын биреп эшләргә. Аннан башка балаларны, башкаларны аңлау мөмкин түгел.



## Маликов Ильнур Иншат улы

1981 нче елда Мөслим районы Күбәк авылында дөньяга килә. 1988 нче елда Күбәк урта мәктәбенә укырга керә, һәм 1998 нче елда уңышлы тәмамлый. Югары белем алу өчен Алабуга педогогия институтының хезмәт тәрбиясе факультетына укырга керә. 2003 нче елда кулына диплом алган яшь белгеч, туган ягына, туган мәктәбенә технология укытучысы булып эшкә кайта. 2006 нчы елда география дәресләре укытырга тәгъдим ителә Ильнур Иншатовичка, янә яңа белем алыр өчен

Чаллы шәһәре укытучыларга өстәмә белем бирү институтында укырга керә, һәм 2008 нче елда тәмамлый. Бүгенге көндә дә Күбәк урта белем бирү мәктәбендә, егетләргә технология фәнен, география фәннәрен укыта.

Ильнур Иншатович балаларга төпле белем бирергә тырыша, эзләнү, яңалыкка омтыла, бүгенге көндә аның укучылары технология һәм география фәннәре буенча олимпиадаларда һәр елны призлы урыннар алып киләләр. Төрле конкурсларда катнашып уңышлы чыгыш ясыйлар, Колубин XXI конкурсларын да призлы урыннар яулыйлар.

Бүгенге көндә дә класс җитәкчесе вазыйфаларын да бик теләп башкара, өч чыгарылыш класс чыгарган укытучы, балаларга ныклы белем, тәрбия бирү өстендә эшли.



## Бәширова Римма Рифкать кызы


1971 нче елның 8 нче августында Актаныш районы Иске Байсар авылында туа.1988 нче елда Иске Байсар урта мәктәбен тәмамлый. 1988-1991 елларда Минзәлә педагогия училищесында укый. Башлангыч сыйныфлар укытучысы белгечлеген алып, мәгариф өлкәсендә эшчәнлеген Мөслим районы Октябрь урта мәктәбендә башлангыч класслар укытучысы булып башлап җибәрә. 1991-1996 елларда Алабуга дәүләт педагогия институтының (ЕГПИ) “Татар теле һәм әдәбияты” бүлегендә читтән торып югары белем ала.

2014-2015 нчеуку елыннан Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбенең филиалы – Октябрь башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшен дәвам итә. Күп еллар мәктәптә укыту дәверендә, укучыларына төпле белем бирергә тырыша, тормышта үз юлларын таба белүче, олылырны хөрмәт итүче чын кешеләр итеп тәрбияләргә омтыла.

Римма Рифкать кызы яңа заман технологияләре белән бергә атлаучы укытучы. Һәр эшне намус белән, җиренә җиткереп башкара белә. Бәйрәм һәм чараларны татар телендә уздыра. Телне саклау, үстерү һәм киләчәк буынга җиткерү өчен үзеннән өлеш кертә. Укучылары фән бәйгеләрендә, фәнни- гамәли конференцияләрдә, төрле конкурсларда даими катнашып җиңүләр яулыйлар. Район һәм республика фән олимпиадаларында җиңүче, призер булдылар.

Өзлексез үз белемен һәм гамәли күнекмәләрен күтәрү өстендә эшли. 2000 нче елда беренче квалификацион дәрәҗә бирелә. “Ел укытучысы”, башка төрле конкурсларда катнашып мактау кәгазьләренә лаек. Римма Рифкать кызы укучыларының яраткан сыйныф җитәкчесе дә. Укучылары башлангычны тәмамлап чыгып китсәләр дә, беренче укытучылары белән һәрдаим элемтәдә. Ул укыткан укучылар аның юлын дәвам итә.

# Нәбиуллина Гөлчәчәк Нәҗип кызы



1985 нче елның 9 нчы декабрендә Актаныш районы Актаныш авылында туган. Биш айлык чагында гаиләсе белән Яр Чаллы шәһәренә күченгән. Урта белемне Яр Чаллы шәһәренең 47 нче һәм 9 нчы номерлы мәктәпләрендә алган. “Мәктәп еллары күңелле кичәләр, дус-сыйныфташлар, эчкерсез укытучылар белән еллар узган саен ерагайса да, Чаллы дәүләт педагогика институтында укыган вакытлары тагы да кадерлерәк кебек”, - ди Гөлчәчәк Нәҗип кызы. Бу уку йортында ул югары белем алып, укытучы дигән бөек һөнәр серләренә төшенгән.

Хезмәт юлын башта балалар бакчасында башлаган, аннан соң Мөслим районы Октябрь авылына тормышка чыгып, Дусай башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә дәвам итә. Хәзерге вакытта Күбәк мәктәбенең филиалы булган Октябрь башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә эшли. Тормыш девизы: "Укытучыга җитмеш төрле һөнәр дә аз", шуны истә тотып, барысына житешергә, һәрнәрсәдән хәбәрдар булырга тырыша. “Эшемдә гаиләмнең терәген һәрчак тоям”, - дип уртаклаша Гөлчәчәк Нәҗип кызы.

# Гәрәева Гөлсинә Габдулла кызы



1973 нче елның 6 нчы апрелендә Нурлат Октябрь районы Яңа Әмзә авылында Габдулла һәм Миңсылу Нәбиуллиннар гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга аваз сала.

Башлангыч мәктәпне, урта белемне туган авылында ала. 1990 нчы елда Яр Чаллы педучилищесына укырга керә. 1992 нче елда уку йортын тәмамлый, кулына диплом ала һәм Мөслим районы Яңа Карамалы авылына тәрбияче булып эшкә кайта. 1995 нче елда балалар бакчасы мөдире вазифасын да алып бара.

2006 нчы елда хезмәт юлын Мөслим районы Иске Карамалы авылы балалар һәм яшүсмерләр өчен “Наз” социаль приютында тәрбияче булып дәвам итә.

2012 нче елда Казанның социаль һәм гуманитар белем бирү институтына психолог белгечлегенә укырга керә. 2018 нче елда Мөслим районы Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбендә педагог- психолог булып эшкә урнаша.

Гөлсинә Габдулла кызы тыйнак, гади, гадел һәм шул ук вакытта таләпчән дә. Ул мәктәптә педагог-психолог һәм сыйныф җитәкчесе булып эшли. Башкарган хезмәт юлында үзен энергияле, оптимист, тапкыр сүзле, бик кешелекле, ярдәмчел кеше буларак күрсәтә. Үзенең һөнәри дәрәҗәсен даими рәвештә үстерә, яңа технологияләр үзләштерә, семинар-тренингларда актив катнаша. Төрле категория балалар һәм ата-аналар белән эшләүдә ярдәм күрсәтә. Укучыларда мәрхәмәтлелек, әдәплелек тәрбияләү, класс җитәкчеләренә, укытучыларга психологик ярдәм күрсәтү кебек эшләрне зур осталык белән башкара. Игелеклелеге, ярдәмчел һәм сизгерлеге аңа төрле кешеләр белән элемтә урнаштырырга ярдәм итә. Һәрвакыт үз коллективы өчен җан атып яши, хезмәттәшләре арасында уртак тел таба.



## Минһаҗева Рузалия Әбүгали кызы

1965 нче елның 23 нче августында Мөслим районы Октябрь авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килгән. 1972-1980 нче елларда Октябрь сигезеллык мәктәбендә белем ала. 1980 нче елда Күбәк урта мәктәбендә укуны дәвам итеп, 1982 нче елда аны тәмамлый. Хезмәт юлын, Күбәк урта мәктәбен тәмамлагач, 1982 – 1983 нче уку елында башлангыч класс укытучысы булып башлый.

1983 - 1985 нче елларда Башкортостан Республикасы Йоматау авыл хуҗалыгы техникумында укып, бухгалтер белгечлеге ала һәм туган авылы Октябрьда авыл хуҗалыгы тармагында эшли башлый. 1986 нчы елнын август аенда Күбәк авылына килен булып төшә. Үзенә белем биргән укытучылары янәшәсендә лаборант һәм эш башкаручы буларак хезмәт юлын дәвам итә. Сайлаган белгечлеге буенча эшлисе килү теләге зур булганлыктан, Иске Карамалы сәүдә оешмасына бухгалтер булып эшкә урнаша. Ул чордагы үзгәреш җилләре Рузалия эшләгән оешмага да кагыла. 1995 нче елнын август аенда кабат мәктәптә, шул ук эшендә хезмәт юлын дәвам итә.

Табигате белән тыныч, сабыр холыклы Рузалия Әбүгали кызы мәктәптә эшләү дәверендә үзен бары тик уңай яктан гына күрсәтә. Үз вазыйфаларын сыйфатлы башкара, зур күләмле эш башкара ала, аларны үтәү нәтиҗәләренә җаваплы карый. Рузалия яңа хәлне анализларга һәм килеп туган проблемаларны хәл итәргә сәләтле. Булдыклы, куелган максатка ирешү буенча оператив карарлар кабул итә белә.

Коммуникация һәм эшлекле мәгълүматны эшкәртү методлары, шул исәптән документлар белән дә эшләүче ышанычлы белгеч. Җитәкченең төрле эшлекле йөкләмәләрен җаваплы һәм намус белән башкара. Мәктәп хезмәткәрләре белән эшлекле, игелекле, дустанә мөнәсәбәтләрдә. Көндәлек эшлекле этика, тәртип кагыйдәләрен һәм нормаларын үтәүдә үрнәк булып тора.


2020 нче елда озак еллар намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы фән һәм мәгариф министрлыгынын Рәхмәт хаты белән бүләкләнә.

Коллективның һәм авылның иҗтимагый тормышында актив катнаша. Күп еллар участок сайлау комиссиясе секретаре булып эшли.



## Абдуллина Равилә Фаяз кызы

1966 нчы елның 7 нче мартында Мөслим районы Үрәзмәт авылында туа. Мәктәптән соң Казан СГПТУ-94 тә почта бүлекчәсенә оператор белгечлеге ала. 1988 нче елда Күбәк авылы егете белән тормыш корып җибәрәләр. 2007 нче елдан хәзерге көнгәчә Күбәк урта мәктәбендә хуҗалык җитәкчесе булып эшли.



## Абдуллина Гөлназ Ринат кызы

1968 нчы елда Мөслим районы Октябрь авылында дөньяга килә. 1975-1985 нче елларда Күбәк урта мәктәбендә белем ала. Укуны тәмамлаганнан соң бер ел колхозда эшли. 1987-1988 нче елларда Түбән Кама шәһәре көллиятендә сатучы һөнәрен үзләштерә.

Укуны тәмамлагач, язмыш җилләре аны Әлмәт шәһәренә китерә, “Алсу” фабрикасында тегүче-мотористка булып хезмәт итә. Соңыннан туган ягына кайтып, “Наз” балалар приютында 8 ел буе аш пешерүче булып эшли. 2015 нче елдан Күбәк урта мәктәбендә аш пешерүче вазыйфаларын башкара.



## Салихова Зөлфия Зиятдин кызы

1971 нче елның 14 нче июлендә Үзбәкстан Республикасында туа. Мәктәптән соң тәрбияче һөнәрен үзләштерә. 1993 нче елда әти-әниләре белән Мөслим районы Яңа Карамалы авылына күченеп кайталар. 1994 нче елда Дусай егете белән тормыш коралар. 2013 нче елның августына кадәр Дусай башлангыч мәктәбендә балаларга белем һәм тәрбия бирә. 2013 нче елдан Күбәк урта мәктәбендә пешекче булып эшли. Ягымлы, тырыш, уңган хезмәткәрне укучылар да, хезмәттәшләре дә хөрмәт итә.

## Исламова Рәүзия Руфат кызы



1962 нче елның 10 нчы февралендә Мөслим районы Исәнсеф авлында туа.

1979 нчы елны урта мәктәпне тәмамлаганнан соң читтән торып Лаеш авыл хуҗалагы техникумында хисапчы һөнәрен үзләштерә. 1981-1985 нче елларда Урожай колхозында хисапчы булып эшли. 1986 нчы елдан 2004 нче елга кадәр Иске Карамалы авылында ПМК оешмасында хисапчы вазифасын алып бара. 2007-2016 нчы елларда Күбәк урта мәктәбендә китапханәче булып эшли. Лаеклы ялда булуына карамастан, бүгенге көнгәчә техник хезмәткәр булып хезмәт куя.



## Госсамова Әлфия Усман кызы

1965 нче елның 5 нче мартында Магнитогорск шәһәрендә эшче гаиләсендә туа. Мәктәптән соң ГПТУ тәмамлый. 1984-1987 нче елларда алган белгечлеге буенча ит комбинатында Яр Чаллы шәһәрендә эшли. 1987 нче елда Мөслим районы Түреш авылы егете белән тормыш корып җибәрәләр. 1995 нче елдан алып хәзерге көнгәчә Күбәк мәктәбендә техник хезмәткәр булып эшли.

## Амирова Лира Ягфәр кызы



1965 нче елның 22 нче декабрендә Мөслим районы Вәрәшбаш авылында туа.1983-1984 нче елларда мәктәптән сон Метрәй мәктәбендә пионервожатый булып эшли. Аннан соң, Бөгелмә кооператив училищесында сатучы һөнәрен үзләштерә. 1989-1996 нчы елларда Иске Карамалы пекарьнясында ипи пешерүче булып эшли. 2008-2014 нче елларда “Наз” социаль приютында да повар булып эшли. 2016 нчы елдан хәзерге көнгәчә Күбәк урта мәктәбендә повар булып хезмәт куя.

## Хафизов Васил Миңлегали улы



1958 нче елның 11 декабрендә Мөслим районы Яңа Сәет авылында туган. Урта белемне Тат. Бүләр авылында ала.1974 нче елда СПТУга укырга керә, һәм 1975нче елда тракторист-машинист һөнәрен алып чыга. Ике ел армия сафларында хезмәт иткәннән соң, Мөслим районы Иске Карамалы авылында урнашкан ПМК-13 оешмасына эшкә урнаша. Үз эшен бик яратып, җиренә җиткереп башкара. 2016 нчы елда Күбәк урта мәктәбенә техник хезмәткәр булып эшкә килә. Лаеклы ялда булсада, бүгенге көндә үз хезмәтен мәктәптә дәвам итә.

## Шаймарданова Фирдәүсә Габдрахман кызы



1964 нче елның 1 нче февралендә Питрәч районы Иске Йорт авылында туган. 10 нчы классны тәмамлаганнан соң колхозда сыер савучы булып эшли. 1983 нче елны Мөслим районы Иске Карамалы авылына килен булып төшә һәм Күбәк урта мәктәбендә повар булып эшли башлый. Хәзерге көнгәчә Фирдәүсә Габдрахман кызы Күбәк урта мәктәбендә техник хезмәткәр булып эшли.

## Мөхәмәдиев Инсаф Тажтдин улы



1967 нче елның 11 нче ноябрендә Мөслим районы Иске Әлмәт авылында туа. Ул башлангыч белемне авылында ала, аннан соң Әмәкәй урта мәктәбендә укуын дәвам итә. Урта мәктәпне 1984 нче елда тәмамлый һәм хезмәт юлын туган колхозында башлап җибәрә. 1985 нче елда Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумына укырга керә. 1988 нче елда агрохимик һәм бухгалтер белгечлекләре алып чыга. 1988 - 1999 нчы елларда Мөслим районы Иске Карамалы авылында, Куйбышев исемендәге колхозда агроном булып эшли.

1990 нчы елда гаилә кора.

2004 нче елның май аеннан Иске Карамалы авылында урнашкан балалар һәм яшүсмерләр өчен “Наз” социаль приютында эшли.  2011 нче елдан  бүгенге көнгә кадәр, Күбәк урта мәктәбендә  оператор булып хезмәт куя. Кайда гына эшләсә дә ул кешеләргә ярдәмчел булуы белән аерылып тора. Эш урынында, ашыгыч хәл итүне таләп итүче очрак булганда да,  ул алыштыргысыз ярдәмче.

Мөхәмәдиев Инсаф Таҗтдин улы кайда гына хезмәт куйса да, үз эшенә җаваплы карый, яратып башкара, кыскасы, үз эшенең остасы. Хезмәттәшләре, авылдашлары аны тыйнак, намуслы булганы өчен хөрмәт итәләр.